**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

«02» 06 2026 ел Яр Чаллы №1806

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә башкарма документацияне формалаштыру һәм алып бару үзенчәлекләре турында

«Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, реконструкцияләгәндә, капиталь ремонтлаганда башкарма документация составын һәм алып бару тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2023 елның 16 маендагы 344/пр номерлы боерыгы, «Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә башкарма документацияне формалаштыру һәм алып бару үзенчәлекләре турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 елның 29 декабрендәге 1751 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясы 1.5 өлешендә каралган башкарма документацияне, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү эшләрен үткәрүне, башкарма документацияне электрон рәвештә булдыру һәм алып бару буенча подрядчының (башкаручының) йөкләмәләрен күздә тоткан контрактка (контракт, шартнамә) кертеп, кәгазьдә кабатламыйча (алга таба – электрон рәвештә башкару документациясе), электрон документлар формасында формалаштыру һәм алып бару тәэмин ителәә.

2. Муниципаль заказчыларга тәкъдим итәргә:

2.1. Җирле бюджетлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү) буенча муниципаль контрактларга подрядчының (башкаручының) башкарма документларны кәгазьдә кабатламыйча, электрон документлар формасында фолрмалаштыру һәм алып бару буенча йөкләмәләрен кертергә;

2.2. Җирле бюджетлар акчаларын җәлеп итеп финанслана торган капиталь төзелеш объектларын төзү (реконструкцияләү) буенча башкарма документларны

формалаштыруны һәм алып баруны электрон документлар формасында тәэмин итәргә;

2.3. Башкарма документацияне алып бару буенча эшне Проектлар белән идарә итү мәгълүмат системасында оештырырга.

3. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү мәсьәләләре буенча урынбасары Д.Ф. Вәлиуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Н. Маняпов